Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский
район, с.Камаево, ул.Дифгата Сирая
д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай  авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай  авылы, Дифгать Сирай
урамы   29А  йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

2020 ел 29 нчы апреленнән № 7

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

“2020 нче елда Менделеевск муниципаль
районының Камай авыл җирлеге
территориясендә язгы ташуга каршы
чараларны әзерләү һәм үткәрү турында”гы
карарны гамәлдән чыгару турында

Закон белән билгеләнгән компетенцияне бозуларны бетерү максатларында Камай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ :

1. Камай авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 12 нче мартында чыгарылган 5 номерлы “ 2020 нче елда Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташуга каршы чараларны әзерләү һәм үткәрү турында”гы карарны гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм www.mendsleevsk.tatar.ru. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы сайтының "Камай авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Камай авыл җирлеге башлыгы: И.И.Әһлиева

1 нче кушымта
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына

Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясендә 2020 елгы язгы ташу чорында мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча оператив штабы СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Әһлиева Инзилә Ильяс кызы | штаб җитәкчесе, Камай авыл җирлеге башлыгы |
| Зиннәтуллина Гүзәлия Мөнир кызы | штаб җитәкчесе урынбасары, Камай авыл җирлеге башкарма комитеты Секретаре |

Штаб әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Иванова Айгөл Шамил кызы | "Камай төп гомуми белем бирү мәктәбе" директоры (килешү буенча) |
| Рәхимова Лилия Наил кызы | Камай авыл мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе (килешү буенча) |
| Галимуллина Гөлфидә Марсель кызы | Китапханәче(килешү буенча) |
| Аннаморадова Римма Борис кызы | мәктәпкәчә эш буенча директор урынбасары (килешү буенча) |
| Әһлиев Динар Рәис улы | «Әһлиев Д. Р» КФХ башлыгы (килешү буенча ) |
| Хайриев Илнур Равил улы | «Хайриев И. Р.» КФХ башлыгы (килешү буенча) |
| Кәлимуллин Рәмис Рафис улы | «Кәлимуллин Р. Р.» КФХ башлыгы (килешү буенча) |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартыннан
5 нче номерлы карарына
.

Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штаб турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш

хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штаб (алга таба-ОШ) язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оешма, предприятие һәм учреждениеләр эшчәнлеген координацияләүче штаттан тыш орган булып тора.

1.2. Эшчәнлекнең аерым юнәлешләре буенча мәсьәләләрне хәл итү өчен штаб җитәкчесе Камай авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләрен эшкә җәлеп итәргә хокуклы.

1.3. Оператив штабны җыю штаб җитәкчесе карары буенча башкарыла. Аның урыны итеп Камай авыл җирлеге башлыгы кабинеты билгеләнә.

## 2. Оператив штаб бурычлары

Оператив штабның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү буенча эшләрне планлаштыру һәм оештыру.

2.2. Халыкны һәм территорияләрне язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм алмашу.

2.3. Прогностик мәгълүмат җыю, гомумиләштерү буенча Менделеевск муниципаль районы оператив штабы һәм күрше авыл җирлекләре җитәкчеләре белән үзара хезмәттәшлек итү.

2.4. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен көч һәм чаралар группировкасын булдыруга штаб җитәкчесенең тәкъдимнәре һәм вариантлары әзерләү.

2.5. Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә эш картасын алып бару өчен кирәкле белешмә материал әзерләү.

2.6. Менделеевск муниципаль районы территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча район оператив штабына тәкъдимнәр әзерләү һәм тапшыру.

2.7. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү мәсьәләләре буенча Менделеевск муниципаль районы ГХМ эшләре бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Менделеевск муниципаль районындагы полициясе белән хезмәттәшлекне оештыру.

2.8 Камай авыл җирлеге территориясендә ташкын сулары күтәрелүгә бәйле хәлләрнең торышын тикшереп тору.

## 3. Оператив штаб функцияләре

ОШ үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1. Хәлне даими контрольдә тота һәм исәпкә алып бара.

3.2. Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә юнәлдерелгән чаралар һәм көчләрне куллану буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша.

3.3. Авыл җирлеге предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча беркетелгән территорияләрдә чараларны тормышка ашыруда эшчәнлеген координацияли.

3.4. Мәгълүмат җыю, эшкәртү, алмашу һәм бирүдә катнаша.

3.5. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча эшләрнең барышы турында докладлар әзерли һәм аларны ташкыннарга каршы район оператив штабына тапшыра.

3.6. Менделеевск муниципаль районының Гражданнар оборонасы эшләре буенча бүлегенең өстәмә көчләрен һәм чараларын җәлеп итү кирәклеген нигезли.

3.7. Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе боерыклары, карарлары проектларын әзерли.

3.8. Гадәттән тыш хәлләрнең торышын, кабул ителгән карарларның, бирелгән һәм алынган күрсәтмәләрнең исәбен хронологик эзлеклелектә алып бара.

3.9. Массакүләм мәгълүмат чараларын язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр турында дөрес һәм оператив мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыра.

3.10. Язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча эшләрне оештыру тәҗрибәсен гомумиләштерә.

4. Оператив штабны формалаштыру, әзерләү һәм эш тәртибе

4.1. ОШ составы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2. Аны Камай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе җитәкли.

4.3. Оператив штабның вазыйфаи затларының функциональ бурычлары эшләнә һәм Камай авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартыннан
5 нче номерлы карарына

Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штабы вазыйфаи затларының функциональ бурычлары

Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штабы җитәкчесе

Язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү эшен оештыру өчен җаваплы.

Бурычлы:

1. оператив штабның эш планын карарга һәм расларга;
2. язгы ташу чорында атнага бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә оператив штаб утырышлары үткәрергә ;
3. Камай авыл җирлеге гражданнарын язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча әзерләүне оештырырга;
4. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә Гражданнар оборонасы хезмәтләре, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең уртак гамәлләре тәртибен билгеләргә;
5. язгы ташу чоры башлану белән җирлек территориясендә гадәттән тыш хәлләрне контрольдә тоту буенча өстәмә чаралар эшләргә
6. гадәттән тыш хәлләрдә халыкка су астында калган территорияләргә вакытлыча керүне тыю турында карар әзерләргә;
7. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат алганда, хәлне бәяләү өчен разведка оештырырга (разведка үткәргәндә су басу мәйданын, аеруча куркыныч участокларны, шулай ук Корылмалар һәм алар өчен янаулар билгеләргә) һәм карар кабул итәргә (Менделеевск муниципаль районының язгы ташуга каршы

оператив штабы белән берлектә);

8. килеп туган хәлгә туры китереп, язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен җәлеп ителә торган службаларның һәм бүлекчәләрнең гамәлләренә төзәтмәләр кертергә ;
9. карарлар кабул итү, хезмәтләргә һәм бүлекчәләргә бурычлар кую, аларның үзара хезмәттәшлеген оештыру һәм бурычларны үтәүне тәэмин итәргә;
10. язгы ташу торышы үзгәрешен күзәтеп торырга;
11. язгы ташу хәле катлауланганда, өстәмә көчләр һәм чаралар җәлеп итәргә, аларны каршы алырга һәм урнаштырырга;
12. Менделеевск муниципаль районының язгы ташуга каршы оператив штабы белән элемтәдә торырга, кабул ителгән чаралар, карарлар һәм язгы ташу торышы турында хәбәр итәргә;
13. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен көч һәм чаралар резервын булдыруны тәэмин итәргә.

Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штаб җитәкчесе урынбасары

Оператив штаб җитәкчесенә буйсына.

Бурычлы:

1. оператив штаб карарларын үтәү, аның булмаганда штабны җитәкләү һәм аның эше өчен җаваплылык тоту;
2. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләр янаганда көч һәм чараларның урнашуын координацияләргә;;
3. язгы ташу хәлен өйрәнергә, разведка оештырырга һәм язгы ташу хәле турында белешмәләр алырга;
4. өстәмә көчләр һәм чаралар җәлеп итү турында тәкъдимнәр кертергә һәм оператив штаб җитәкчесе күрсәтмәләрен тапшыруны тәэмин итәргә;
5. оператив штаб җитәкчесенә разведка нәтиҗәләре һәм язгы ташу вәзгыяте турында алынган хәбәрләрне җиткерү ;
6. язгы ташу ситуациясе катлауланган очракта, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итәргә һәм аларны оператив штаб җитәкчесенә чираттагы доклад белән башкарырга;
7. оператив штаб җитәкчесе күрсәтмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

8. язгы ташу хәле катлауланганда районның махсус хезмәтләре чакыртырга һәм алар белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга;
9. язгы ташу чорында оператив штаб буенча җаваплы затларның дежур тору графигын эшләргә.

Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча оператив штабы әгъзалары

Оператив штаб җитәкчесенә һәм оператив штаб җитәкчесе урынбасарына буйсына.

Бурычлылар:

1. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җәлеп ителә торган оешма, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре белән телефон элемтәсен сакларга;
2. язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм бетерүдә катнашучы оешма, предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә өстәмә көчләр һәм чаралар җәлеп итү турында тәкъдимнәр кертергә һәм оператив штаб җитәкчесе күрсәтмәләрен тапшыруны тәэмин итәргә;
3. оператив штаб җитәкчесенә язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрнең торышы һәм аларны бетерү барышы турында разведка нәтиҗәләре һәм алына торган белешмәләр бирергә ;
4. оператив штаб җитәкчесе һәм аның урынбасарының турыдан-туры күрсәтмәсе буенча эш итәргә.

4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 елның 12 мартыннан
5 нче номерлы карарына

2020 елга Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясендә язгы ташуга каршы чараларны әзерләү һәм үткәрү ПЛАНЫ

| № | Үткәрелә торган чаралар | башкаручы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|

| п/п | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | 2020 елда җирлек территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычын киметү һәм язгы ташу нәтиҗәләрен йомшарту чаралары буенча Камай авыл җирлеге көчләренең һәм чараларының әзерлеге торышы турында" темасына оператив штаб утырышы үткәрү. | Оператив штаб җитәкчесе | Март |
| 2 | «Язгы ташу чорында язгы ташуга каршы чаралар әзерләү һәм үткәрү турында " гы мәсьәлә буенча халык белән очрашу үткәрү | Оператив штаб җитәкчесе, штаб әгъзалары | язгы ташу чорына кадәр |
| 3 | Язгы ташу чорда сулыкларда һәм елгаларда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм куркынычсызлык чаралары буенча гомуми белем бирү мәктәбе укучылары белән дәресләр үткәрүне оештырырга. | штаб әгъзалары, укытучылар | язгы ташу чорында |
| 4 | Барлык социаль объектларның түбәләрен һәм якын-тирә территорияләрен чистартуны оештырырга . | Учреждение җитәкчеләре, штаб әгъзалары | язгы ташу чорында |
| 5 | Күпер корылмаларының, юл полотносы астында су үткәргеч торбаларның торышын һәм аларны ташкыннар һәм ташкыннарны аварияез үткәрүгә әзерлекләрен тикшерүне оештырырга | Оператив штаб җитәкчесе | язгы ташу чорында |
| 6 | Терлекләрне, орлык фондын, фуражны, минераль ашламалар, техника һәм башка җиһазларны саклау буенча чаралар күрү.<br>Хуҗалык территориясендә урнашкан терлекчелек һәм склад биналарының түбәләрен, стеналарын, шулай ук су үткәрү торбаларын һәм күперләрне кардан чистартуны оештыру.<br>Кирәкле азык, фураж, салам запасы булдыру . | КФХ башлыклары | язгы ташу чорында |
| 7 | Йорт тирәсендәге карны, йорт янындагы су торбаларын чистарту, азык-төлекне базлардан вакытында чыгару буенча халык белән эшне оештырырга. | штаб әгъзалары | язгы ташу чорында |
| 8 | Возжайка елгасы сулыкларындагы бәхетсезлек очракларын кисәтү буенча халык арасында агитация чараларын кулланып эш оештыру | штаб әгъзалары | язгы ташу чорында |
| 9 | Менделеевск муниципаль районы администрациясенең ГО һәм ГТХМ | Оператив штаб җитәкчесе | язгы ташу чорында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | буенча кизү торучылары белән даими элемтәдә торырга | | |
| 10 | Су басу зоналарында җәмәгать тәртибен һәм халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү. | Оператив штаб җитәкчесе , штаб әгъзалары, полиция участок инспекторы | язгы ташу чорында |